| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.01.2020 п.г.т.Алексеевское № 6

**«Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсын уздыру буенча муниципаль конкурс комиссиясе эшен төзү һәм раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы «Татарстан Республикасы елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы һәм «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе президиумы карары белән расланган «Татарстан Республикасы елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмә нигезендә 2020 елның 9 гыйнварындагы ПР-157-1 номерлы карары белән,

**карар кылам:**

1. «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын уздыру буенча муниципаль конкурс комиссиясе төзергә һәм аның эш регламентын расларга (1, 2 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 17 гыйнварындагы
6 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының муниципаль конкурс комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

**Комиссия рәисе:**
Кадыйров Н.К. - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе

**Комиссия рәисе урынбасары:**
Свистунов И.К. - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)

**Комиссия секретаре:**
Зубрилова О.В. - Алексеевск шәһәр җирлеге советы рәисе урынбасары (килешү буенча)

**Комиссия әгъзалары:**
Новикова А.А. - Алексеевск муниципаль районының «Форпост» МБУ директоры (килешү буенча)
Йосыпова Г.А. - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының эшләр идарәчесе.

**Башкарма комитет**
**эшләре идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 17 гыйнварындагы
6 номерлы карарына
2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын уздыру буенча муниципаль конкурс комиссиясе эш регламенты**

1. Әгәр муниципаль конкурс комиссиясе утырышында исемлек составының кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы була.

2. Муниципаль конкурс комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен комиссия әгъзаларының 50 проценттан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигезлеге очрагында хәлиткеч комиссиянең рәисе тавышы була.

3. Муниципаль конкурс комиссиясе карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә һәм Комиссия рәисе һәм әгъзалары тарафыннан Комиссия утырышы узган көннән алып эш көннәрендә санала торган өч көн эчендә имзалана.

4. Муниципаль конкурс комиссиясе эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә заявкаларны кабул итү срогы башланган көннән башлап конкурсның I этабында катнашуга гаризаларны кабул итә һәм теркәп бара.

5. Муниципаль конкурс комиссиясе эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә заявкалар кабул итү тәмамланган көннән алып конкурсның I этабында катнашуга тапшырылган гаризаларны «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында нигезләмәнең 4 нче кушымтасы нигезендә критерийларга туры китереп бәяли һәм конкурсның II этабында катнашуга дәгъва кылучы катнашучыларны вәкаләтле орган билгеләгән тәртиптә билгели.

6. Конкурсның I этабын уздыру йомгаклары буенча муниципаль конкурс комиссиясе Конкурсның II этабына тапшырыла:

1) «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы Положениегә 2.1 нче кушымта нигезендә Конкурсның II этабында катнашу турында гариза;

2) муниципаль конкурс комиссиясе төзелгән һәм аның составы расланган муниципаль хокукый акт күчермәсен;

3) Конкурсның I этабында катнашучыларның барысы исемлеге;

4) муниципаль конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан имзаланган муниципаль конкурс комиссиясе утырышының йомгаклау беркетмәсе;

5) «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәнең 3.9 пункты нигезендә конкурсның II этабында катнашуга дәгъва кылучы катнашучыларның гаризалары.

7. Муниципаль конкурс комиссиясе карарларына законнарда билгеләнгән тәртиптә катнашучылар һәм дәгъвачылар тарафыннан шикаять бирелергә мөмкин.

**Башкарма комитет эшләре идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**